| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ПИСЬМЯНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ПИСМӘН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

№34 2021 елның «17» декабре

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджеты турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елга бюджетының теп характеристикаларын расларга:

1) «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең фаразланыла торган гомуми күләмен 13 403 270 сум итеп;

2) «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының фаразланыла торган гомуми күләмен 13 403 270 сум итеп;

3) «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын 0 сум итеп.

2. 2023 һәм 2024 еллар план чорына «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетының теп характеристикаларын расларга:

1) «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетының 2023 елга фаразланучы керемнәренең гомуми күләме 13 394 380 сум һәм 2024 елга 13 360 160 сум күләмендә фаразлана;

2) 2023 елга «Писмән авыл җирлеге» бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 13 394 380 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар-332 180 сум һәм 2024 елга 13 360 160 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар-662 450 сум;

3) Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге бюджеты кытлыгын - 2023 елга 0 мең сум һәм 2024 елга 0 мең сум күләмендә.

3. 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

4. 2023 елның 1 гыйнварына расларга:

«Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең эчке бурычының иң югары чиген 0 сум итеп, шул исәптән «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нуль күрсәткече белән расларга;

5. 2024 елның 1 гыйнварына расларга:

«Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең эчке бурычының иң югары чиген 0 сум итеп, шул исәптән «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге

муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нуль күрсәткече белән расларга;

6. 2025 елның 1 гыйнварына расларга:

«Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең эчке бурычының иң югары чиген 0 сум итеп, шул исәптән «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль гарантияләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген Россия Федерациясе валютасында нуль күрсәткече белән расларга;

7. «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына фаразланган керем күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

8. 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

9. «Писмән авыл җирлеге» бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

10. «Писмән авыл җирлеге» бюджетының 2022 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә 0 сум, 2023 елга 0 сум һәм 2024 елга 0 сум күләмендә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга.

11. 2022 елга авыл җирлеге халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итүне оештыру өчен шартлар тудыру буенча чараларны тәэмин итү өчен 1 679 300 сум күләмендә, 2023 елга 1 688 900 сум күләмендә һәм 2024 елга 1 698 800 сум күләмендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджетына әлеге пунктта каралган башка бюджетара трансфертлар ай саен тигез елешләр белән башкарыла.

12. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә «Писмән авыл җирлеге» бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен 2022 елда 33 400 сум һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына 47 300 һәм 46 600 сум күләмендә расларга.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджетына әлеге пунктта каралган башка бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләр белән башкарыла.

13. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә 2022 елга, төзелгән килешүләр нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, җирлек бюджетыннан Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле субсидияләр күләмен 8 976 970 сум күләмендә һәм 2023, 2024 еллар план чорына 8 926 080 сум һәм 8 863 200 сум күләмендә расларга.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы бюджетына әлеге пунктта каралган субсидияләр ай саен тигез өлешләр белән башкарыла.

14. «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан 2022 елда 103 800 сум, 2023 елның план чорына 107 300 сум һәм 2024 елга 111 160 сум күләмендә бюджетара трансфертларны расларга, шул исәптән:

- 2022 елда җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә 0 сум, план чорына 2023 елга 0 сум һәм 2024 елга 0 сум күләмендә дотацияләр;

- 2022 елда хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга 103 800 сум, план чорына 2023 елга 107 300 сум һәм 2024 елга 111 160 сум күләмендә субвенцияләр.

15. Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары 2022 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең саны артуга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел, мондый карарларны «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына яңа функцияләр һәм вәкаләтләр бирү белән бәйле рәвештә кабул итү очракларыннан тыш.

16.Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Лениногорск районы һәм Лениногорск шәһәре территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

17. «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларының 2022 елның 1 гыйнварына «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар шартлары нигезендә 2021 елда түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактларның файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә калдыгы «Писмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2022 елда күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

18. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Писмән авылы, гагарин урамы, 5 йорт, Иске Писмән авылы Үзәк урам 50 йорт – авыл мәдәният йорты 1нче йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

19. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.В.Насретдинов